# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**(IV чакырылыш)**

## КАРАРЫ

**егерме сигезенче утырыш**

**18 май 2023 ел** **№90** **Иске Җөри авылы**

### Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 11 апрелендәге 10/13-09/1765 номерлы хатын карап, Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең - физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач.

2. Гамәлдән чыккан дип танырга:

- Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең 15.11.2021 №39 «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» карары;

- Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 16.01.2023 № 82 «Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең 15.11.2021 №39 «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар

буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм үзенең гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков

СОВЕТ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ